**Шәһәр күләмендә җәмгыять белеме фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы 10-11 нче сыйныф**

**Эш вакыты – 120 минут**
**Гомуми балл – 98**

**1. Лингвистик конструктор. Тәкъдим ителгән сүзләрдән төшенчәнең билгеләмәсен төзегез һәм язып куегыз. Ул төшенчәгә аңлатма бирегез. Төшенчәне атаган өчен 2 балл. Билгеләмә төзегән өчен 1 балл. Төшенчә дөрес аталмалмаган очракта бәяләнми. Барлыгы 9 балл.**

1.1. Халыкның, икенчесе, бер, этник йотылу, чыгуы, тулысынча, тарафыннан, юкка, йотылып.

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

1.2. Башка, үз асылын, кешенең, кешеләрдән, кушылмасы, үзенчәлекләре, аерымлыгын, психологик, тәшкил итә торган.

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

1.3. Яшәү рәвешенә, ташлап киткән, бер мәдәниятне, башкаларның, илне, һәм, кыйммәтләренә, ярашмаган, төркемне, кеше.

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

**2. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавапның астына сызыгыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

**2.1. Демократик режимны аерып торган билге нәрсә?**

1) законнарның төрле тармаклы системасы булу
2) сайлаучыларның сайлауларга күпләп килүе
3) сәяси мәйданда төрле партия һәм хәрәкәтләрнең конкурентлыгы
4) сайлауларны хөкүмәт матбугатында яктырту

**2.2. “Һәркем үз мөмкинлекләрен һәм мөлкәтен эшмәкәрлек һәм закон белән тыелмаган башка төрле икътисади эшчәнлек өчен ирекле файдаланырга хокуклы” дигән эшмәкәрлек ирege принцибы РФнең кайсы документында теркәлгән?**

1) РФ Конституциясендә
2) РФ Салым кодексында
3) РФ Бюджет кодексында
4) РФ Гражданлык кодексында
5) РФ Административ кодексында

**2.3. Дәүләтнең эчке җитештерүчеләр мәнфәгатьләрен чит ил конкурентларыннан яклауга юнәлтелгән сәясәт ул:**

1) капитализм
2) индустриализм
3) протекционизм
4) монополизм
5) олигополия

**2.4. РФ Конституциясе буенча Россия Федерациясендә мөстәкыйльлек һәм хакимиятнең бердәнбер чыганагы булып кем тора?**

1) президент
2) хакимият
3) халык
4) җәмгыять

**2.5. Милек һәм җирне файдалану нигезендә милекчегә килә торган керем:**

1) Пошлина
2) Табыш
3) Рента
4) Дивидендт
5) Хезмәт хакы

**3. Икътисади мәсьәләне чишегез. Исәпләүләр күрсәтелгән өчен 3 балл (Исәпләүсез 1 балл). Барлыгы 6 балл.**

3.1. А иленең экспорты – 102 000 долларга, ә импорты 31875 долларга тигез иде; Б иленең экспорты шул ук елда – 835 000 доллар, ә импорты 1 562 000 доллар булды. А һәм Б илләренең тышкы сәүдә балансы сальдосын санап чыгарыгыз һәм чагыштырыгыз.

Җавап:______________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

3.2. Ниязга ике елдан соң коммерция курсларында укыр өчен 116 640 мең акча кирәк булачак. Әгәр банкның еллык проценты 8 % булса, аңа ике елдан соң кирәкле акча җыяр өчен күпме акча салырга кирәк булачак?

Җавап:________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

**4. Курсив белән билгеләнгән урыннарны җәмгыять белеме атамасы белән алыштырыгыз. Дөрес җавап өчен 3 балл. Барлыгы 6 балл.**

4.1. Үзара аңлашылмаучылык, "ике чукрак сөйләшүе" гаилә тормышында *капма-каршы якларның карашлары, фикерләре бәрелешүе* һәм канәгатьсезлек тудыручы мөһим бер сәбәп булып тора.

**Җавап: ________________**

4.2. Бүгенге көндә билгеле булган бер генә җәмгыять тә катып калмаган, алар һәрчак үзгәрешләр кичергән, әлеге процесслар вакытында социаль *системаларның элементлары югарыдан түбәнгә таба барган тәртип* торышлары шик астына куелган.

**Җавап: _________________**

**5. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз. Барлыгы 6 балл.**

5.1. Аерылышкан вакытта танылган язучының хатыны ире белән бергә яшәгән вакытта чыгарылган китапларны, аның мораль ярдәме белән барлыкка килгән бердәм милек дип дәлилләргә тырыша. **Әлеге кешеләр арасында бернинди никах килешүе төзелмәгән, сезнеңчә суд нинди карар чыгарыр? Үз җавабыгызны аңлатыгыз (3 балл).**

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

5.2. Балалар мәйданчыгында машина куелган. Бала уйнаган вакытта машинаның ишегенә туп белән бәрә. Машинаның хуҗасы баланың ата-анасына ремонт өчен акчалата дәгъва белдерә. **Машина хуҗасының дәгъвасы хокуклымы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз (3 балл).**

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

**6. Түбәндә китерелгән ситуацияләр эшсезлекнең кайсы типларына туры килүен билгеләгез. Һәрбер ситуациянең номерын тиешле баганага язып куегыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 7 балл.**

1. Эшчене икътисадта рецессия булуы аркасында эштән алалар
2. Эшчене производствода яңа технологияләр кертү аркасында эштән алалар
3. Бухгалтер үз теләге белән яхшырак түләнелә торган эш табу максатыннан эштән китә
4. Фабрика хезмәткәре тәкъдимнең тискәре (негатив) шогы аркасында эштән алына
5. Фармацевт үзенә уңайлы графиклы эш таба, ләкин әлегә анда эшли башламаган
6. Программист башка шәһәргә күчү сәбәпле эштән китә
7. Электрик яктырту кертү аркасында фонарщик профессиясе кирәксез булып кала

Җавап:

| Фрикцион | Циклик | Структур |
|---|---|---|
| | | |

**7. Анаграмманы чишегез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 6 балл.**

1. ЯЦЕФДЛЯИ – икътисадта бәяләрнең төшү процессы

________________________________

2. ЗТАЯМОРИАЦИ – тузган (износ) әйберләрнең бәясен, продукт бәясенә күчерү

_____________________________

3. ТЯГӘМЫҖЬ – Пятницаны очратканга кадәр, Робинзон Крузо моннан читтә иде

__________________________

4. ЯИНТАҖЬ – үзлеген күрсәтер өчен Раскольников әлеге адымны ясарга батырчылык итте

__________________________

5. ККЧЗЫАОНЫЛ – төп гомуми хокук принципларының берсе

__________________________

6. БУКСРЕПЛИА - әлеге идарә итү формасындагы дәүләттә, аш пешерүче дә дәүләт башлыгына дәгъва итә ала

___________________________

**8. Тәкъдим ителгән тексттагы хаталарны төзәтегез. Тапкан хата өчен 1 балл. Дөрес төзәтү өчен 2 балл. Барлыгы 15 балл.**

Федераль закон кешене, аның хокукларын һәм ирекләрен иң югары кыйммәт дип тану принцибын беркетә.

Безнең һәрберебез ил гражданы булып тора яки, билгеләнгән кагыйдәләргә таянып, гражданга әверелә ала. Үзебезнең дәүләт территориясендә туу һәм әти-әниләрнең ил гражданнары булу безгә Россия гражданы булырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш гражданлыкка кабул итәргә дә мөмкиннәр. Моның өчен кеше махсус гаризада гражданлыкка кабул итүне сорап мөрәҗәгать итә һәм карарны субъект җитәкчеләре чыгара.

14 яшькә җиткән һәр кеше дә мондый хокукка ия. Әмма монда бик мөһим шарт бар – кеше РФда 10 ел дәвамында даими яшәгән булырга тиеш.

30 нчы елларда кертелгән паспорт кешенең Россия гражданы булуын раслаучы документ була. Россия гражданы булган кеше теркәлгән барлык хокукларга һәм бурычларга ия була. Безнең хокукларның һәм ирекләрнең төп гаранты булып РФ Хөкүмәте тора.

**Җавап:**

| | **Хата** | **Төзәтү** |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| 3. | | |
| 4. | | |
| 5. | | |

**9. РФнең дәүләт хакимияте органнары һәм аңа караган хакимият тармаклары арасындагы тәңгәллекне ачыклагыз: беренче баганада бирелгән һәр позициягә икенче баганада туры килә торган позицияне сайлап алыгыз. Һәрбер дөрес тәңгәллек өчен 1 балл. Барлыгы 6 балл.**

| **РФ дәүләт хакимияте органнары** | **Дәүләт хакимияте тармаклары** |
|---|---|
| **А) Казан шәһәре администрациясе** | **1) Закон чыгаручы хакимият** |
| **Б) Федераль Җыелыш** | **2) Башкарма хакимият** |
| **В) РФ юстиция министрлыгы** | |

| | |
|---|---|
| **Г) Дәүләт Думасы** | |
| **Д) РФ Хөкүмәте** | |
| **Е) Казан шәһәренең мәгариф идарәсе** | |

**Җавабыгызны таблицага языгыз:**

| А | Б | В | Г | Д | Е |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**10. Текстны укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез. Барлыгы 11 балл.**

Бу халыкара оешманы булдыру идеясе Беренче бөтендөнья сугышыннан соң барлыкка килгән. Эре хәрби катаклизмнарны илләрнең берләшүе нәтиҗәсендә булдырмау юлларын һәм бурычларын, сугыш елларында ук Австрия графы Рихард Куденхове-Калерги белдергән иде. Бу идеяне тормышка ашыру өчен шактый киң җәмәгатьчелек хәрәкәте барлыкка килде. Әлеге оешмага Советлар Россиясенең кушылуы хакында бәхәсләр дә уздырылган.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң әлеге оешманың проектын төзүгә француз җәмәгать эшлеклесе Жанн Монне яңа этәргеч ясый. Ул әлеге берләшүне (интеграцияне) икътисадый өлкәдән башларга кирәк дигән фикерне белдерде.

Интеграция процессы Салкын сугыш тәмамлану белән көчәйде, илләр икътисадый берләшү союзыннан, бердәм сәяси киңлек булдыруга күчтеләр. Хәзерге вакытта оешма эчке һәм тышкы чакырулар белән бәйле булган кайбер кыенлыклар кичерә, бу үз чиратында аның язмышы турында бик күп бәхәсләр тудыра.

**1) Текстта нинди оешма турында сүз бара? 2 балл.**

Җавап:

______________________________________________________________________

**2) Текстта телгә алынган икътисадый берләшү (союз) кайсы елда төзелде? (1 балл) Ул ничек дип атала? (1 балл) Сәяси киңлек (союз) кайсы елда төзелгән? (1 балл)**

Җавап:_______________________________________________________________

______________________________________________________________________

**3) Текстта оешманың эчке һәм тышкы чакырулар белән бәйле булган заманча проблемалары турында әйтелә. Бер (эчке һәм тышкы) шундый проблема (2 балл), аның характеристикасын (2 балл) һәм барлыкка килү сәбәпләрен (2 балл) языгыз. Барлыгы 6 балл.**

Җавап:____________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

**11. Хәзерге дөньяда булган сәяси режим төрләрен һәм аларга хас булган үзенчәлекләрне билгеләгез, һәрбер төркемне конкрет илнең мисалы белән тәңгәлләштерегез. Түбәндә китерелгән элементларның тәртип саннарын таблицаның тиешле буш урыннарына куегыз. Һәрбер дөрес төркем өчен 2 балл. Ялгыш булганда 0 балл. Барлыгы 6 балл.**

| | **1 төркем** | **2 төркем** | **3 төркем** |
|---|---|---|---|
| Режим (тәртип) төре | | | |
| Режимның үзенчәлекле сыйфатлары | | | «Халык тарафыннан һәм халык өчен сайланылган халык хөкүмәте» |
| Илләр мисалы | | Тунис | |

1. Тоталитар
2. Авторитар
3. Швеция
4. «Барысы да дәүләтнең эчендә, дәүләттән тыш һәм дәүләткә каршы берни дә юк»
5. Корея халык демократик республикасы (КНДР)
6. Демократик
7. «Сәясәттән башка барлык башка нәрсәләр рөхсәт ителә»

**12. Татар халкының күренекле шәхесләренең исемнәрен атагыз һәм кыскача аларның татар дөньясына керткән өлешен тасвирлагыз. Дөрес исем өчен 2 балл. Керткән өлешләрен тасвирлау өчен 3 балл. Барлыгы 15 балл.**

**1.** **2.** **3.**





**1.**

**2.**

**3.**